

Мәктәпкәчә тәрбия учреждения-ләренен топ бурычы - баланы һәрьяклап тәрбияләнvне тәэмин итv. Бvгенге кондә балалар бакчасында эшләvчеләр алдында торган бурычларнын ин моһиме торле милләт балаларына максатчан рәвештә халкыбызнын vткәне, матур гореф-гадәтләре, тирә-як моһите, теле, сәнгате, тарихы белән таныштыру.

«Балачак» («Детство») Рузаевка муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирv учреждениесенен «Татар Пешләсе авылы балалар бакчасы» структур бvлекчәсендә торле милләт вәкилләре тәрбияләнә.  Бу бакчага татарлар белән бергә торле телле балалар йори. Тәрбиячеләр аларны татар, рус һәм  мордва халкы мәдәнияты белән таныштыралар, торле халыкларнын биюләрен ойрәтәләр, жырларын жырлыйлар, уеннарын балалар белән бергәләп уйныйлар һәм vткәрелгән чаралар да татар, рус, мордва телләрендә оештырыла. Бередә татар мәдәнияты музее эшли.

Районда ин яхшы балалар бакчасынын берсе буларак, алдынгы эш тәжрибәсе белән уртаклашу максатын тормышка ашырып, 21 мартта республикабыз балалар бакчаларыннан 65 житәкчене семинарга чакырганнар. Шул исәптән, Мордовия мәгариф министрлыгыннан Татьяна Николаевна Зайцева, Рузаевка муниципаль районы администрациясендә «Мәгариф идарәсе» житәкчесе Венера Раис кызы Ларина, Мордовия халкынын Дуслык Йорты житәкчесе Раиса Ивановна Акашкина һәм башкалар семинарда катнашты.



Семинарнын темасы: «Мәдәниятле белем бирv пространствосы шартларында мәктәпкәчә яшьтәге балаларда этномәдәни компетентлылык формалаштыру». Чара бу бакча эше турындагы видеопрезентацияне Зульфия Хәйдар кызы Копасова житәкчелегендә таныштыру белән башланды. Аннары Венера Раис кызы семинарны тантаналы ачты. Кереш сvзне Татьяна Николаевна әйткәч, Елена Николаевна Галешева

житәкчелегендә Татар Пешлә бакчасында тәрбияләнvче балалар бик матур «Шома бас» бию композициясен kvрсәттеләр. Семинарга әзерлек вакытында «Балачак» дигән Рузаевка муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирv учреждениесенен бюджет акчасына балаларга сигез (4 - малай, 4 - кыз) һәм ике алып баручы татар костюмнарын тектергәннәр. Сокланып туймаслык татар киемнәрен киеп югары әзерлекле тәрбиячеләр Галия Рафаил кызы Саитова белән Диана Рашит кызы Муратова татарча да, русча да семинарны алып бардылар. Диана Рашит кызы кон темасын ачыклап зур доклад ясады. Ә инде Диана Рашит кызы Муратова белән Маргарита Рафаил кызы Жалилова тәрбияләгән балалар «Оч кыз» татар халык әкиятеннән озекне kvзләргә яшьләр китерерлек иттереп сәхнәләштерделәр. Олкән группадагылары белән Диана Рашит кызы «Кояш нурлары» дигән тvгәрәк алып бара. Анда ул мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар мәдәниятына якынайту остендә эшли: халкыбызнын vткәне, гореф-гадәтләре, тирә-як моһите, теле, сәнгате, тарихы белән таныштыра. Бу тvгәрәккә балалар яратып йориләр. Галия Рафаил кызы Саитова белән Диана Рашит кызы Муратова, Елена Ивановна Галешева «Яратыгыз» жырын башкарулары семинарда катнашучыларнын kvнелләренә хуш килде.
Шулай ук Рузаевка шәһәре һәм районы балалар бакчалары тәрбиячеләре мордва мәдәнияты рухында тәрбияләv алымнары буенча мастер-классларын kvрсәттеләр, милли курчак ясау аша балаларнын ижатын vстерv kvнекмәләре булдыру һәм башка эш торләре тәжрибәләре белән уртаклаштылар.
Семинарга нәтижәләр ясаганда, Раиса Ивановна Акашкина «Татар Пешләсе авылы балалар бакчасы» структур бvлекчәсен унышлы житәк-ләгән Галия Хәйдар кызы Дубинниковага Благодарность тапшырды. Чарада катнашучыларнын һәрберсе Татар Пешләсе балалар бакчасы эшенә югары бәя бирделәр, vзләренә кирәкле материалны алдылар, эш тәжрибәләрендә кулланырга дип фотога да тошереп йорделәр. Шулай, бер-берсен баетып, эш тәжрибәләре белән уртаклаштылар.
Татар Пешләсе балалар бакчасы житәкчесе Галия Хәйдар кызы Дубинникова әнгәмәсендә: «Дvрт елдан артык инде матур зур бина, иркен бvлмәләр, барлык таләпләргә жавап кайтарган пищеблок, физкультура-музыкаль зал, логопед бvлмәсе, медицина блогы бар, - дип тозеп китте бакча житәкчесе Галия Хәйдаровна. - Эчтәлекле тәрбия эшләребез зур vрләрне яулап килә: Рузаевка районы балалар бакчалары арасында оештырылган конкурста «Трудовое соперничество» кубогын яуладык, kvпторле конкурсларда (муниципаль, республика, регионара, халыкара) жинvчеләребез житәрлек. Мәсәлән, «Тере сvз» дигән республика конкурсында Айсель Шатаевабыз, татар телендә сәнгатьле шигырь сойләп, абсолют жинvче булды, - ди житәкче унышларына шатланып.
- Бакчабызда милли музей эшли. Анда торле милләт халкы киемнәренә киендерелгән курчаклар, милли татар киемнәре һәм башка жиһазлар бар. Татар телен, мәдәниятын группадагы татар милләтле балага гына тvгел, рус, мордваларына да житкерәбез. Балаларга тел ойрәтvдә топ алымнарнын берсе - халкыбызнын әдәби мирасына, фольклорына таяну. Шуна kvрә Тукай атналыгы, Карга боткалары, Татар Пешлә Сабантуй бәйрәмнәрендә катнашуларны гадәткә керттек».
Менә шулай Рузаевка районы Татар Пешләсе балалар бакчасында милли-мәдәни тәрбия бирәләр.

**Наилә Насырова**